КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 декабрь

г.Казань

№ 1139

2024 елда «Компрессор» транспорт-күчереп утырту узелын ясау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елда «Компрессор» транспорт-күчереп утырту узелын ясау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 16 декабрь, 1139 нчы
карары белән расланды

2024 елда «Компрессор» транспорт-күчереп утырту узелын ясау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм 2024 елда «Компрессор» транспорт-күчереп утырту узелын ясау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба шул ук – субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Субсидия әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

Каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлеше – «Компрессор» транспорт-күчереп утырту узелын ясау эшләрен башкару өчен өстәлгән кыйммәткә салым исәпкә алынмаган чыгымнар.

Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

3. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

заявка – сайлап алуда катнашу өчен әлеге Тәртипнең таләпләре нигезендә кәгазьдә рәсмиләштерелеп тапшырыла торган документлар;

сайлап алуда катнашучылар – Министрлыкка әлеге Тәртип нигезендә рәсмиләштерелгән заявка тапшырган юридик затлар (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш);

субсидия алучы – сайлап алуда җиңүче дип танылган сайлап алуда катнашучы;

килешү – Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул

ителгән субсидия алучы арасында төзелә торган Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында килешү.

Әлеге Тәртиптә кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.

4. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү, заявкалар бирелә башлаган датага кадәрге бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе бюджет системасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталында һәм Министрлыкның рәсми сайтында түбәндәгеләр күрсәтелеп урнаштырыла:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкаларны бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасы. Шул ук вакытта заявкалар кабул итүне тәмамлау датасы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 17 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсе;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләре;

әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә сайлап алу критерийлары;

әлеге Тәртипнең 6 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан әлеге Тәртипнең 7 пункты нигезендә әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

заявкалар бирү тәртибе һәм әлеге Тәртипнең 7 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе; эшләп бетерү өчен заявкаларны кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кабул итмәү тәртибе, шулай ук әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә аларны кабул итмәү нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында субсидия бирү күләме, әлеге Тәртипнең 14 пункты нигезендә субсидия күләмен исәпләү тәртибе;

әлеге Тәртипнең 9 – 12 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан килешүгә имза куелырга тиешле срок;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.

Сайлап алу сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 5 һәм 6 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килүеннән, шулай ук заявкалар керүнең чиратлылыгыннан чыгып, тәкъдимнәр соратып алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

5. Сайлап алуда катнашучы түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:

сайлап алуда катнашучы үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра;

сайлап алуда катнашучы Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли.

6. Заявка бирү аена кадәрге айның 1нче көненә карата сайлап алуда катнашучы туры килергә тиешле таләпләр:

сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

сайлап алуда катнашучының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы юк (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучыга кушу, башка юридик затка кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау;

сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормый;

сайлап алуда катнашучы экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

сайлап алуда катнашучы Берләшкән Милләт Оешмасы (алга таба – БМО) уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

сайлап алуда катнашучы «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый.

7. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срокта заявка бирә.

Сайлап алуда катнашучы Министрлыкка түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 5 һәм 6 пунктларында күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат бирелгән, түбәндәге документлар теркәлгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада язылган заявка бирә:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка һәм сайлап алуга бәйле сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастыруга (урнаштыруга) ризалык;

заявка бирелгән айга кадәрге айның 1енче көненә карата Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган, билгеләнгән тәртиптә расланган өземтә (сайлап алуда катнашучы тарафыннан мондый документ тапшырылмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль соратып ала);

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имза куелган «Компрессор» транспорт-күчеп утырту узелын ясауга тотылган чыгымнар турында белешмә кәгазе;

объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамәләр күчермәләре, объект буенча җыелма смета исәп-хисаплары күчермәләре, сайлап алуда катнашучының объектны төзүгә факттагы чыгымнарын раслый торган документлар күчермәләре (КС-2 формасы буенча башкарылган эшләрне кабул итү турында актлар күчермәләре, КС-3 формасы буенча башкарылган эшләр кыйммәте һәм чыгымнар турында белешмә кәгазьләре күчермәләре);

заявка бирелгән айга кадәрге айның 1нче көненә карата сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмауны раслый торган салым органының белешмә кәгазе (сайлап алуда катнашучы тарафыннан мондый документ тапшырылмаган очракта,

Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

заявка бирелгән айга кадәрге айның 1енче көненә карата дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан сайлап алуда катнашучының дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчесе, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы заты яки баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмавын раслый торган өземтә (сайлап алуда катнашучы тарафыннан мондый документ тапшырылмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имза куелган башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмау турында белешмә кәгазе (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән очраклардан тыш);

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имза куелган сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавын раслый торган белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имза куелган сайлап алуда катнашучының офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имза куелган сайлап алуда катнашучының үзгәртеп оештыру (башка юридик затны сайлап алуда катнашучы юридик затка кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавы, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәве, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавы турында белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имза куелган сайлап алуда катнашучының экстремистик эшчәнлеккә яисә терроризмга катнашлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавын, БМО Уставының VII бүлеге, БМО Куркынычсызлык советы яки БМО Куркынычсызлык советының махсус карарлары белән төзелгән органнар, террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән бәйле яисә массакүләм юк итү коралын таратуга бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлекләре белән каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында төзелә торган вәкаләтләр булмавын, «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормавын раслый торган белешмә кәгазе.

Заявканың барлык битләре номерланган булырга тиеш. Заявка тегелгән һәм, кәгазьләрнең гомуми саны күрсәтелеп, сайлап алуда катнашучының яки ул вәкаләтләр биргән затның имзасы һәм заявканың икенче ягында сайлап алуда катнашучының мөһере (булганда) белән расланырга тиеш.

Министрлыкка тапшырыла торган мәгълүматлар дөрес булмаган, шулай ук

документларны ялганлап ясаган өчен сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

8. Министрлык әлеге Тәртипнең 7 пунктында каралган заявкаларны һәм документларны кабул итә һәм, заявкалар кергән датаны һәм вакытны күрсәтеп, алар кергән көннән алып бер эш көне эчендә заявкаларны теркәү журналында терки. Заявкага, аның Министрлыкка керү чиратына карап, тәртип номеры бирелә.

Сайлап алуда катнашучы заявкага үзгәрешләр кертергә хокуклы:

заявканы кире алу турында хәбәрнамәдән һәм алга таба яңа заявка булдырылганнан соң, заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көнгә кадәр;

Министрлыкның заявканы эшләп бетерүгә кире кайтару турындагы карары буенча заявканы карап тикшерү этабында.

Заявкага үзгәрешләр керткәннән соң яки заявканы кире алганнан соң заявканы кабат бирү сайлап алуда катнашучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән сайлап алуда катнашучының заявка бирү тәртибе кебек гамәлгә ашырыла.

Төзәтмәләр кертелгән заявка сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявка эшләп бетерүгә кире кайтарылганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча кабат җибәрелә.

9. Заявкалар кабул итү срогы тәмамланган көннән алып ике эш көненнән артмаган срокта Министрлык заявкаларны Министрлыкка керү чираты тәртибендә сайлап алуда катнашучыларның әлеге Тәртипнең 5 һәм 6 пунктларында каралган сайлап алу критерийларына һәм таләпләренә туры килү-килмәвенә тикшерә, шулай ук әлеге Тәртипнең 7 пункты нигезендә заявка составында тапшырылган документларны тикшерүне гамәлгә ашыра.

Заявканы карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итүмәү өчен нигезләр:

сайлауда катнашучының сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

сайлап алуда катнашучы биргән заявкаларның һәм (яки) документларның сайлап алу турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

заявка составында тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе.

10. Сайлап алуны уздыру нәтиҗәләре буенча Министрлык сайлап алуның җиңүчесен билгели һәм әлеге Тәртипнең 9 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән срок тәмамланган көннән алып өч эш көненнән артмаган срокта субсидия бирү турында йә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

11. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.

12. Кабул ителгән карарның нәтиҗәләре турында хәбәрнамә сайлап алуда катнашучыга Министрлык тарафыннан язма рәвештә тиешле карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә электрон почта яисә заявкада күрсәтелгән почта адресы аша җибәрелә.

13. Министрлык, субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, түбәндәге мәгълүматлардан гыйбарәт сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында, шулай ук үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

субсидия бирүдән баш тарткан сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат, баш тартуның сәбәпләрен, шул исәптән мондый сайлап алуда катнашучыларның заявкаларына туры килми торган сайлап алу уздыру турындагы белдерүләр нигезләмәләрен күрсәтеп;

килешү төзелә торган субсидия алучыларның исемнәре һәм аларга бирелә торган субсидиянең күләме.

14. Субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$\text{С} = \frac{\text{З(юл)} + \text{З(рт)}}{2} - \text{З(рт)},$$

монда:

З(юл) – «Компрессор» транспорт-күчереп утырту узелын ясау эшләрен башкару өчен субсидия алучы тарафыннан фактта башкарылган һәм документаль расланган чыгымнар (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча);

З(рт) – коммуникацияләр үткәреп, автобуслар һәм җиңел автомобильләр өчен килү юлларын оештырып, «Компрессор» транспорт-күчереп утырту узелы янындагы, тимер юлның юл буе полосалары чикләрендәге муниципаль территорияне төзекләндерү эшләрен башкару өчен Татарстан Республикасының фактта башкарылган һәм документаль расланган чыгымнары (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча).

Шул ук вакытта субсидия күләме Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларыннан арта алмый.

15. Субсидия бирү килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешү Министрлык белән субсидия алучы арасында Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә төзелә.

Әгәр субсидия алучы килешүгә әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән срокта кул куймаган булса, ул килешү төзүдән баш тарткан дип санала.

Субсидия алучы кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, килешүгә, анда хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелеп, йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Министрлыкка элек җиткерелгән лимитлары киметелгән очракта, килешүгә килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча уртак фикергә ирешелмәгәндә килешүне өзү турында шарт кертелә.

Кирәк булганда Министрлык белән субсидия алучы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

16. Субсидия, субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 10 нчы эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидия алучы тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә яки кредит оешмасында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетына күчерелә.

17. Субсидия бирү нәтиҗәсе – объектны файдалануга тапшырганнан соң 12 ай эчендә шәһәр яны тимер юл транспортында юл йөрү өчен юл йөрү документлары (билетлар) белән «Компрессор» транспорт-күчереп утырту узелыннан утыртып җибәрелгән пассажирлар санын, шул ук объектны файдалануга тапшырганга кадәрге чор белән чагыштырып караганда, кимендә 10 процентка арттыру.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү срогы – 2024 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

18. Субсидия алучы Министрлыкка, хисап кварталыннан соң килә торган айның 20сеннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган килешүнең бертип формасында билгеләнгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра.

19. Министрлык субсидия алучы тарафыннан хисап җибәрелгән көннән 20 эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 18 пункты нигезендә субсидия алучы тарафыннан тапышырлган хисапны тикшерә.

Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) тикшерә. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

20. Бирелгән субсидия, аны биргәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган субсидия бирү шартлары субсидия алучы тарафыннан бозылган очракта, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта, Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән алып 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

21. Субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 20 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогы бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны

Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

22. Субсидия алучы тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган мәгълүматның һәм документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучы җитәкчесенә йөкләнә.

23. Субсидияне файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

______________________________